**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **20.11.2025 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенә керүче Түбән Стәрле авылында 2026 елда үзара салым жыюны кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пунктында гражданнар җыены:

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнар,көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:
   - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (ком-вак таш катнашмасын сатып алу, төяү, ташу, салу, Кызыл таң урамындагы юлны профильләштерү)

3. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Тубэн Стәрле авылы, Кызыл тан ур., 19 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы: Сабиржанова Л.С.